БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 21 » июль 2018 ел № 260

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын раслау турында» 2017 елның 9 февралендәге 80 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

Балтач муниципаль районы халкының пассажирлар йөртүгә һәм транспорт хезмәтенә булган ихтыяҗын канәгатьләндерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясына, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законга, ««Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китереп, «Җайга салынулы тарифлар буенча муниципаль маршрутларда халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыруга бәйле чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 елның 18 июнендәге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, яңа муниципаль автобус маршрутларын урнаштыру зарурилыгы белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын раслау турында» 2017 елның 9 февралендәге 80 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә автомобиль

транспортында пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрына үзгәрешләр кертергә һәм кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы<br>
Балтач район башкарма комитеты<br>
җитәкчесе Р. И. Шакиров